Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Олы Ачасыр авыл җирлеге Советы 2017 елның 26 гыйнварындагы 96 номерлы өченче чакырылыш утыз беренче утырышы карары

# «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Олы Ачасыр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

**Олы Ачасыр авылы**
**2017 ел**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ОЛЫ АЧАСЫР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**КАРАР**

**өченче чакырылыш утыз беренче утырышы**

**26 нчы гыйнвар 2017 ел** **№96** **Олы Ачасыр авылы**

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Олы Ачасыр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

Зеленодольск муниципаль районы Олы Ачасыр авыл җирлеге башлыгы М. Г. Гатиятуллинның мәгълүматын тыңлап һәм фикер алышканнан соң Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Олы Ачасыр авыл җирлеге Советының 2005 елның 28 июнендәге 123 номерлы «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Олы Ачасыр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» гы карары проекты буенча ачык тыңлаулар билгеләү турында карар проектына, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Олы Ачасыр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 18, 87-89 номерлы статьялары, «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Олы Ачасыр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә ачык тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмәгә таянып, Олы Ачасыр авыл җирлеге Советы **карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Олы Ачасыр авыл җирлеге Советының 2005 елның 28 июнендәге 123 номерлы карары (Олы Ачасыр авыл җирлеге Советының 2006 елның 6 октябрендәге 35 номерлы, 2007 елның 5 маендагы 72 номерлы, 2009 елның 5 маендагы 162 номерлы, 2010 елның 31 августындагы 235 номерлы, 2012 елның 27 мартындагы 61 номерлы, 2012 елның 8 декабрендәге 104 номерлы, 2014 елның 26 мартындагы 176 номерлы,

2015 елның 6 мартындагы 227 номерлы, 2016 елның 18 гыйнвардагы 37 номерлы, 2016 елның 27 июнендәге 61 номерлы карарлар редакциясендә), түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1) 6.1 статьяда:

1.1) 6.1 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 14 пункт өстәргә:

«14) «Россия Федерациясендә хокук бозуларны профилактикалау системасы нигезләре турында» 2016 елның 23 июнендәге 182-ФЗ номерлы Федераль законда каралган хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә чараларны гамәлгә ашыру.

2) 42 статьяда:

2.1) 42 статьяның 16 пунктын 17 пункт диеп санарга, 16 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«16) Муниципаль-хосусый партнерлык проектын гамәлгә ашыру турында муниципаль-хосусый партнерлык өлкәсендә карарлар кабул итә, әгәр ачыктан-ачык партнер булып муниципаль берәмлек торса, йә муниципаль берәмлек катнашында уртак конкурс уздыру планлаштырыла (Россия Федерациясе, Россия Федерациясе субъекты катнашында уртак конкурс уздыру планлаштырыла торган очраклардан тыш), шулай ук «Дәүләт-хосусый партнерлык турында» 2015 елның 13 июлендәге 224-ФЗ номерлы Федераль законда каралган башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру, «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Олы Ачасыр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль закон, башка федераль законнар һәм Россия Федерациясенең норматив хокукый актлары, Россия Федерациясе субъектларының норматив хокукый актлары, «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Олы Ачасыр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы белән, «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында»).

2.2) 16.1) «Россия Федерациясендә дәүләт-хосусый партнерлык, муниципаль-хосусый партнерлык һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында»2015 елның 13 июлендәге 224-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясындагы 2 өлешендә каралган вәкаләтләрне гамәлгә ашыруга вәкаләтле җирле үзидарә органы билгели;»;

2.3) 16.2) «Россия Федерациясендә дәүләт - хосусый партнерлык, муниципаль-хосусый партнерлык һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында»2015 елның 13 июлендәге 224-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясындагы 2-5 өлешләре нигезендә проектның нәтиҗәлелеген бәяләү һәм аның чагыштырма өстенлеген билгеләү өчен Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органына муниципаль-хосусый партнерлык проектын җибәрә;»;

3) 47 статьяда:

3.1) 47 статьяның 10 пунктын 11 пунктны, 10 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10) хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә:

- хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә муниципаль хокукый актлар кабул итә;

- хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә координация органнары булдыра;

- хокук бозулар кылуга китерә торган сәбәпләрне һәм шартларны бетерү буенча чаралар күрә;

- муниципаль берәмлек территориясендә хокук бозуларны профилактикалауда катнашучы затларның үзара хезмәттәшлеген тәэмин итә;

- «Россия Федерациясендә хокук бозуларны профилактикалау системасы нигезләре турында» 2016 елның 23 июнендәге 182-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясындагы 1 өлешенең 1, 7-10 пунктларында каралган хокук бозуларны профилактикалауны гамәлгә ашыра;

- хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә башка хокукларны гамәлгә ашыра;»;

2. Әлеге карарны законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәве өчен җибәрергә.

3. Әлеге карарны, дәүләт теркәвенә алынганнан соң, Интернет челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре составындагы Зеленодольск муниципаль районы мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru), шулай ук мәгълүмат Олы Ачасыр авыл җирлеге мәгълүмат стендларында: Олы Ачасыр авылы, Үзәк урамы, 46 йорт (җирлек хакимияте бинасы), Олы Ачасыр авылы, Кооператив урамы, 26 йорт (авыл мәдәният йорты бинасы) урнаштырырга.

4. Әлеге карар «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясындагы 8 өлеше, «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Олы Ачасыр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 87 статьясындагы 2, 3 пунктлары нигезендә үз көченә керә дип билгеләргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Олы Ачасыр авыл җирлеге башлыгы Гатиятуллин М.Г. йөкләргә.

**Олы Ачасыр авыл жирлеге**
**башлыгы, Совет рәисе** **М.Г. Гатиятуллин**